ДҮШӘМБЕ
26 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 46 (5846)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, тенге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ҖАВАПЛЫ ҺӘМ МАКТАУЛЫ ЭШ

Сталинчыл өченче бишьеллыкта республикабызда 4.290 километр юллар төзелергә, автотранспортның киң хәрәкәте тәэмин ителергә тиеш. Бу, республикабызның барлык хезмәт ияләре алдында гаят зур һәм җаваплы бурычларның берсе булып тора.

Юллар төзелеше мәсьәләсе шушы көннәрдә ВКП(б) Өлкә Комитетының бюро утырышында каралды. Өлкә Комитет бюросы, Ферганә тәҗрибәсен республикабызның юллар төзелешенә күчерү турында Столбище районы колхозчылары инициативасын яхшы дип тапты һәм бу башлангычны барлык районнарда да куллану буенча үзенең конкрет күрсәтмәләрен бирде. Юл төзелеше эшенә оператив җитәкчелек итү өчен ВКП(б) Өлкә Комитеты янында махсус комиссия төзелде.

Столбище районы колхозчылары инициативасы республикабызның колхозларында, МТС ларында һәм күп кенә предприятиеләрендә зур күтәренкелек белән каршыланды. Төзек һәм культуралы юллар өчен башланган гүзәл хәрәкәткә әледән-әле яңа районнар, яңа колхозлар кушылалар. Алар үзара социалистик ярыш договорлары төзиләр, үз өсләренә конкрет йөкләмәләр алалар. Партия һәм совет оешмалары юллар төзелеше мәсьәләсе белән, элеккегә караганда, җиддиерәк шөгыльләнә башладылар. Бу эшне турыдан-туры үз кулларына алалар.

Беренче нәтиҗәләр күз алдында. Төзү материаллары хәзерләү һәм аларны эш объектларына ташу шактый көчәйде. Мәсәлән, бу елның 1 нче февраленә барлыгы 19.200 кубометр төзү материаллары ташылган булса, 20 нче февральгә ул 35.880 кубометрга җитте. Төзү материаллары ташуның еллык план үтәлеше 57,5 процент тәшкил итә. Узган ел белән чагыштырганда үсеш—37,5 процент. Бондюг, Балтач, Арча, Чаллы кебек байтак кына районнар бу эшне аеруча яхшы итеп оештырдылар. Алар төзү материаллары ташуны 15 нче мартка, ә төзелеш эшләрен орденлы республикабызның данлыклы XX еллыгына тулы үтәү өчен көрәшәләр.

Ферганә каналы төзелеше тәҗрибәсен юллар төзелешенә күчерү буенча бөтен халык хәрәкәте инициаторларын, бу өлкәдә аеруча алдынгылык күрсәткән колхозларны, юл төзелеше бригадаларын, район юл бүлекләрен, машина-юл станцияләрен һәм юл төзелеше участкыларын 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашу өчен сайлап алу турында Күргәзмәнең Баш Комитеты карары масса активлыгын тагын да югары күтәрде.

Беренче кандидатлар билгеләнделәр дә инде. „13 лет Октября", „Память Ленина" (Столбище районы), „Кызыл Байрак", „Яңа Туйма" (Бондюг районы) колхозлары, район юл бүлеге мөдирләреннән: Гафаров, Шәмгуллин, Муллагалиев, Зарифуллин, Колафатова, юл төзү инженерларыннан: Лебедев, Летягин, Егоров, Бесспалов, колхоз бригадирларыннан: Мөхәммәтҗанов, Җәгфаров һәм башка иптәшләр күргәзмәдә катнашу өчен беренче кандидатлар итеп расландылар.

Хәзер алда торган бурыч—бу алдынгылар тәҗрибәсен барлык участкыларга күчерүдән, төзек һәм культуралы юллар өчен башланган ярыш байрагын тагын да югарырак күтәрүдән, ярыш договоры буенча алган йөкләмәләрнең тулы үтәлүен тәэмин итүдән гыйбарәт. Партия, совет, комсомол оешмалары бу эшне чын-чынлап үз кулларына алырга, юл төзү эше планын үтәү өчен бөтен көчне, барлык мөмкинлекләрне тупларга тиешләр.

Бу өлкәдә сәүдә оешмалары һәм промышленность предприятиеләре дә юл төзүчеләргә зур булышлык күрсәтә алалар һәм күрсәтергә тиешләр. Чистай шәһәрендәге кайбер промышленность предприятиеләре моны инде практик эш белән күрсәттеләр. Алар юл төзүчеләргә конкрет ярдәм оештырдылар. Гомуми ял көннәрендә массовый күләмдә юл төзелеше эшенә чыгуны киң кулланалар. Бу башлангычны башка районнарда да кулланырга кирәк.

Юлларның төзеклегенә зур игтибар биргән һәм бу өлкәдә инде кайбер уңышлы нәтиҗәләргә ирешкән районнар республикабызда байтак саналалар. Шуның белән бергә бу өлкәдә әле артта калучы районнар да юк түгел. Мондыйлар рәтенә Балык Бистәсе, Лаеш, Биләр, Аксубай, Октябрь, Бөгелмә, Алексеевский районнарын кертергә мөмкин.

Дөресен әйтергә кирәк: бу районнарда партия, совет оешмаларының җитәкчеләре юл төзелеше эшенә тиешле игтибарны биреп җиткермиләр. Бу гаят зур һәм катлаулы эш белән алар очраклы рәвештә генә шөгыльләнәләр. Артта калучылыкның төп сәбәбен әнә шуннан эзләргә кирәк.

Юллар төзелеше сезонына хәзерлек эшләре җаваплы чорга керде. Март ае—хәл иткеч ай. Билгеләнгән эш күләмен тулы үтәү өчен янадан 24.000 кубометр төзү материаллары ташырга кирәк. Моны үз вактында башкарып чыгу өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Эш тик җитәкчеләрдә, аларның бу эшне кирәгенчә оештыра белүләрендә генә.

ВКП(б) райкомнары һәм барлык башлангыч партоешмалар юл төзелешендә эшләүчеләр арасында политик-тәрбия эшләрен киң җәелдерергә, юл төзелеше эшенә колхозчыларның массовый чыгышларын оештырырга һәм ТАССР ның XX еллыгы хөрмәтенә юл төзелеше эшләре планын вактыннан элек, югары сыйфатлы итеп үтәү өчен социалистик ярышка җитәкчелек итәргә тиешләр.

Ферганә каналы төзелеше тәҗрибәсен яхшы үзләштерү нигезендә, 1940 нчы елда юллар төзелеше планының арттырып үтәлүен тәэмин итик. Бу мактаулы эшне уңышлы рәвештә башкарып чыгу өчен барлык мөмкинлекләрдән файдаланыйк!

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе Баш Комитеты карары буенча Зур Алтын медаль һәм Кечкенә Алтын медаль белән бүләкләнгән иптәшләрдән бер төркем. Өстәге рәттә (сулдан): Зур Алтын медаль белән бүләкләнгән академик В. П. Мосолов, Зур Алтын медаль белән бүләкләнгән Гафур Садриев (Актаныш МТС ы бригадиры, хәзер шул ук МТС ның директоры); Зур Алтын медаль белән бүләкләнгән Гобәйдулла Ганиев (Актаныш МТС ы бригадиры); Зур Алтын медаль белән бүләкләнгән Рамазан Гәрәев (Актаныш МТС ы тракторчысы); Астагы рәттә (сулдан): Зур Алтын медаль белән бүләкләнгән Мөбарәкша Дәүләтшин (Тымытык МТС ы комбайнчысы); Кечкенә Алтын медаль белән бүләкләнгән Галиәскар Гәрәев (Актаныш МТС ының элеккеге директоры, хәзер Юртыш МТС ы директоры); Кечкенә Алтын медаль белән бүләкләнгән Разия Юсупова (Биектау районы, Шушар племхозы сыер саучысы); Кечкенә Алтын медаль белән бүләкләнгән Әкрәм Сафин (Актаныш район җир бүлегенең баш агрономы) иптәшләр.

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Казан гарнизоны сугышчыларын, командирларын һәм политработникларын бүләкләү турында

Хәрби һәм политик хәзерлек эшендәге югары күрсәткечләре өчен, Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы уңае белән, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының мактау грамотасы белән бүләкләргә:

1. Капитан Матвей Васильевич **Труновны.**
2. Лейтенант Александр Егорович **Соломоновны.**
3. Политрук Иван Васильевич **Ковтунны.**
4. Лейтенант Алексей Семенович **Бердниковны.**
5. Лейтенант Александр Васильевич **Гусевны.**
6. Кече командир Константин Васильевич **Минеевне.**
7. Политрук Григорий Федорович **Горбоконьны.**
8. Кече лейтенант Сидор Маркович **Кулинны.**
9. Лейтенант Владимир Васильевич **Петровны.**
10. Өлкән политрук Александр Яковлевич **Поповны.**
11. Капитан Григорий Иванович **Смирновны.**
12. Политрук урынбасары Яков Менделеевич **Голодны.**
13. Кызыл армеец Дмитрий Андреевич **Богомоловны.**

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе
Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы секретаре
өчен Г. ИШМОРАТОВА.

Казан, Кремль.
23 февраль, 1940 ел.

ТАСС ның ЮККА ЧЫГАРУЫ

1. Рейтер агентлыгы үзенең Стокһольмдагы хәбәрчесенең гүяки, „Финляндиянең чик буендагы шоссе юлыннан 5 миль ераклыкта урнашкан Паяла исемле швед авылына 7 совет самолетының 10 фугаслы һәм күп санда яндыра торган бомбалар ташлаган" дигән хәбәрен тарата.

Паяла авылы өстендә һәм гомумән Швеция территориясе өстендә бер генә совет самолетының да очмаганлыгын, ә совет самолетлары турында Рейтер агентлыгы белдерүенең усал ният белән эшләнгән ялган икәнлеген белдерергә ТАСС ның вәкаләте бар.

2. Франциянең Гавас агентлыгы, Франциянең һәм Англиянең кайбер газеталары, шулай ук Германиянең аерым газеталары СССР га яңа диңгез базалары бирү турында, „хәрби базалар" ның санын арттыру һ. б. турында Советлар Союзының Эстония, Латвия һәм Литва алдына таләпләр куйганлыгы турында ялган хәбәрләр тараталар.

Бу хәбәрләрнең барсының да бер нәрсәгә дә нигезләнмәгәнлеген һәм бөтенләй уйдырма икәнлеген белдерергә ТАСС ның вәкаләте бар.

Тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда яхшы күрсәткечләр бирүче алдынгылар һәм стахановчыларның республика почет тактасына ВКП(б) райкомнары һәм хезмәт ияләре депутатларының район советлары башкарма комитетларының күрсәтүләре буенча кертеләләр:

34. Дөбъяз районының Юртыш МТС ы тракторчылары **М. Вафина, С. Ибатуллина, Р. Галәвиев** һәм **Н. Камалиев** иптәшләр тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны 1939 нчы елның 15 нче декабренә тәгәлләделәр.

35. Минзәлә МТС ының трактор бригадасы бригадиры **С. Садреттинов** һәм аның ярдәмчесе **А. Абдрахманов** иптәшләр. Аларның бригадасы тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны 1940 нчы елның 10 нчы январена тәгәлләде. Шушы бригададагы тракторчы иптәш **Г. Гәрәев** норманы көн саен 320 процент үтәде.

36. Минзәлә районы Маткавыш МТС ының 8 нче номерлы трактор бригадасында эшләүче тракторчы иптәш **Н. М. Долгов** үзенә беркетелгән тракторга ремонт ясауны 1940 нчы елның 25 нче январена тәгәлләде.

37. Минзәлә МТС ының тимерчесе иптәш **Н. Дударь** норманы көн саен 161 процент үти.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

ЯҢА УҢЫШЛАРНЫ ЯУЛАП АЛЫРБЫЗ

АКТАНЫШ, 25 февраль. (Телефон буенча). Районның хезмәт ияләре бу көннәрдә чиксез зур шатлык кичерә. МТС, хөкүмәтебезнең бөек бүләге—Ленин ордены белән бүләкләнде. Районның Авыл хуҗалыгы алдынгыларыннан Гобәйдулла Ганиев, Рамазан Гәрәев һәм Гафур Садриев иптәшләр Зур Алтын медаль белән, Галиәскар Гәрәев, Даниил Кузницов, Гомәр Мамашев иптәшләр Кечкенә Алтын медаль белән бүләкләнделәр. Мин дә Кечкенә Алтын медаль белән бүләкләнү бәхтенә ирештем.

Бу шатлыклы хәбәрләр районыбызның барлык почмакларына таралды.

МТС та, бригадаларда кыр эшләренә хәзерлек буенча кызу эш кайный. Колхозларда язгы чәчүне үрнәк рәвештә хәзерлек белән каршылау өчен нык лы көрәш бара. Районда 43 колхоз язгы чәчү өчен барлык кирәкләрне хәзерләп, бүгеннән чәчүгә чыгарга хәзер тора.

Ләкин болар әле алда торган зур эшләрнең башлангычы гына. Без быел район буенча бөртекле культураларның һәр гектарыннан 16 шар центнер уңыш алуга ирешү турында йөкләмә алдык. Партиябез һәм хөкүмәтебезнең безгә күрсәткән зур ышанычы белән рухланган хәлдә бу йөкләмәне без тулысынча һәм арттырып үтәрбез. Машиналардан файдалану, Сталинчыл иген уңышын яулап алу һәм социалистик терлекчелекне үстерү буенча тагын да зуррак уңышларны яулап алырбыз. Партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең бөек ышанычын намус белән акларбыз.

Бу бөек бүләкләр өчен партиябезгә, хөкүмәтебезгә һәм даһи юлбашчыбыз, якын дустыбыз иптәш Сталинга чиксез зур рәхмәт!

Әкрәм Сафин.
Актаныш район җир бүлегенең баш агрономы.

КОЛХОЗЛАР ҮЗАРА ЯРДӘМЛӘШӘЛӘР

ТӘМТЕ. (Телефон буенча). Колхозларның чәчү орлыгы белән бер-берсенә ярдәм итүләре массовый төстә бара. „Зорька" колхозы Мичурин исемендәге колхозга 25 центнер бодай һәм „Ясная Поляна" колхозына 31 центнер чәчүлек солы белән ярдәм итте. „Алга" колхозы „Восток" колхозына 25 центнер бодай һәм 15 центнер солы орлыгы бирде. „Яңа юл" колхозы „Первое Мая" колхозына 60 центнер солы орлыгы белән ярдәм итте.

Районда 18 колхоз үзләреннән артык 1.185 центнер чәчү орлыгын, 1940 нчы елның уңышыннан түләү шарты белән, башка колхозларга бирделәр. Шушы тәртиптә күп кенә колхозлар үзләрендә җитмәгән чәчү орлыкларын хәзерләделәр. Районда 44 колхозның 22 сендә барлык төр чәчү орлыклары җитәрлек хәзерләнде. Колхозларның чәчү орлыгы белән үзара ярдәмләшүләре дәвам итә.

Агроном Осипов.

***

ЧИСТАЙ. (Телефон буенча). „Завет Ильича" колхозы язгы чәчү өчен чәчү орлыгын җитәрлек хәзерләп куйды. Колхоз үзеннән арткан чәчү орлыклары белән башка колхозларга ярдәм итә. „Красный Партизан" колхозына 20 центнер, „Строитель" колхозына 39 центнер һәм Сталин исемендәге колхозга 10 центнер бодай орлыгы бирде.

Агроном *Грашин.*

ЭСТОНИЯ РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ XXII ЕЛЛЫГЫ УҢАЕ БЕЛӘН М. И. КАЛИНИН ҺӘМ В. М. МОЛОТОВ ИПТӘШЛӘРНЕҢ КОТЛАУЛАРЫ

Шушы елның 24 нче февралендә Эстония республикасына XXII ел тулу уңае белән ССР Союзы Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш М. И. Калинин Эстония республикасы президенты К. Пятс әфәндегә котлау телеграммасы җибәрде.

Шул ук вакытта Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш В. М. Молотов та Эстониянең чит ил эшләре министре А. Пийп әфәндегә котлау телеграммасы җибәрде.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАЛАРЫ

23 нче февральдә фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады. Карелия бугазында көчле буран һәм томан булу сугыш хәрәкәтләренә кыенлык тудырдылар. Безнең частьләр дошманның 12 ныгытылган оборона пунктын алдылар, шуларның 4 се тимер-бетоннан ясалган артиллерия корылмалары.

Һава начар булганлыктан авиациянең хәрәкәте разведка очышлары белән генә чикләнде.

***

24 нче февральдә Карелия бугазында көчле рәвештә кар яуу һәм томан булу безнең гаскәрләрнең сугыш хәрәкәтләренә комачаулык итте. Безнең гаскәрләр фронтта дошманның 28 ныгытылган оборона пунктын алдылар, шуларның 19 ы тимер-бетоннан ясалган артиллерия корылмалары.

Безнең частьләр тимер-бетон корылмалары белән бик нык ныгытылган Койвисто (Бьерке), Трурин-Саари һәм Пии-Саари атауларын сугышып алдылар. Атауларда 22 орудие (шуларның 12 се башняле авыр, 10 һәм 6 дюймлы яр буе орудиеләре), кыр һәм зенит орудиеләре, күп санда станоклы пулеметлар, сугыш кирәк-яраклары складлары кулга төшерелде.

Фронтның башка участкыларында әһәмиятле үзгәрешләр булмады.

Һава начар булганлыктан безнең авиациянең хәрәкәтләре разведка очышлары белән генә чикләнде.

ЯХШЫ ЭШЛИЛӘР

Югары иген уңышы яулап алу өчен Кукмара районының Стаханов исемендәге һәм „Электро", „Город коммунар" колхозлары үзара ярышка чыктылар. Бу колхозларда чәчүлек орлыкларны чистарту тәгәлләнде. Барлык авыл хуҗалыгы машиналары ремонттан чыкты. Ефремовчы звенолар оештырылды. Звенолар кышкы агротехника чараларын нык лап уздыруга керештеләр. Колхозчылар өчен агроукулар оештырылды.

„Электро" колхозында агротехник иптәш Абдуллин 7 занятие үткәрде инде. Түгәрәкләрдә 107 кеше укый.

Стаханов исемендәге колхозда агротехник иптәш Әхмәтҗанов 14 занятие үткәрде. Укуга 48 кеше йөри. Тирес чыгаруда эшләүче Ш. Хорамшин, Г. Сабирҗанов иптәшләр көнлек норманы 140 процент итеп үтиләр. Тирес өюдә эшләүче Ш. Ханов, Н. Мозаффаров һәм Н. Абдуллин иптәшләр көнлек норманы 180—190 процентка үтиләр.

„Город коммунар" колхозында Мария Кузьмина һәм Анисия Васильева иптәшләр тирес чыгаруда көнлек норманы 150 процентка үтиләр. Иптәш Л. Иванов бригадасы 150 тонна урнына 180 тонна тирес чыгарды, көл җыю планын 100 процент үтәде.

Г. Мусин.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

РАЙКОМ ПЛЕНУМЫНЫҢ ЧЛЕННАРЫ ТУРЫНДА

ВКП(б) ның Әлмәт райкомында оештыру - инструкторлык бүлеге башлангыч партоешмаларның эшләрен тикшерү, аларга булышлык итү һәм башка мәсьәләләр буенча райком пленумы членнары белән системалы эш алып бара. Элек райкомның оператив эшенә сирәк катнашучы иптәшләрнең күбесе актив эшкә тартылганнар.

Мисальгә Газизов, Зәкиев һәм Долгов иптәшләрне күрсәтергә мөмкин. Оештыру - инструкторлык бүлеге төзелгәнче бу иптәшләр райкомның оператив эшенә бик аз катнашалар иде. Бүлек төзелгәч, алар системалы рәвештә поручениеләр ала башладылар һәм аларны вактында үтәп, райкомга зур булышлык күрсәтәләр.

Ләкин ачык әйтергә кирәк: райкомның башка бүлекләре пленум членнарын оператив эшкә тарту һәм аларны җитәкчелек эшенә өйрәтү мәсьәләсе белән бик начар шөгыльләнәләр. Пленум членнарының бер өлеше (Җаббарова, Шакиров иптәшләр) райком эшенә тиешенчә тартылмаганнар.

ВКП(б) уставы буенча шәһәр һәм район комитетларының пленумнары ай ярымга бер тапкыр чакырылырга тиеш. Әлмәт райкомында менә бу билгеләнгән кагыйдәне бозу фактлары бар. Узган елны райком пленумы бары 4 кенә тапкыр чакырылган.

Райком секретарьлары пленум утырышларын актив киңәшмәсенә әйләндереп җибәргәннәр. Шулай итеп, алар пленумның әһәмиятен, пленум членнарының җитәкчелек рольләрен кечрәйткәннәр. Райкомның январь пленумында членнардан 11 һәм активлардан 41 кешенең катнашуын күрсәтү моңа ачык мисаль булып тора.

ВКП(б) ның район конференциясе бу җидди кимчелекләрне кискен тәнкыйть астына алырга һәм пленум членнары белән эшләүне яхшырту чараларын билгеләргә тиеш.

З. Салахеттинов.

САЙЛАУЛАР ХРОНИКАСЫ

Апас районындагы 21 башлангыч партоешмада отчет-сайлау җыелышлары үткәрелде. Җыелышларда коммунистлар актив катнаштылар.

„Комсомолец" колхозының коммунистлары оешма секретаре иптәш Габитовның колхозларга йомшак җитәкчелек итүен, партия тарихын үзлегеннән өйрәнүчеләргә булышлык күрсәтмәвен нык тәнкыйть иттеләр. Җыелыш секретарьның эшен канәгатьләнмәслек дип тапты һәм яңа секретарь сайлады.

Чүри-Бураш МТС ы партоешмасының отчет-сайлау җыелышында фикер алышуларга катнашучы стахановчы бригадир иптәш Абдуллин партоешма секретаре иптәш Фроловның кадрларны өйрәнмәве турында сөйләде. МТС та производство алдынгылары күп. Ләкин алар арасында партия-масса эше алып барылмый. Соңгы 5 айда партоешма ВКП(б) сафларына бер кеше дә кабул итмәгән.

Партоешманың секретаре итеп иптәш Гыйсмәтуллин сайланды.

Биләр районының барлык 24 партоешмасында отчет - сайлау җыелышлары тәмам булды. Җыелышларда фикер алышуларга коммунистларның 66 проценты катнашты.

26 нчы февральдә партиянең район конференциясе ачыла.

☘

Актаныш районының барлык башлангыч партоешмаларында отчет-сайлау җыелышлары булып үтте. 11 оешмада секретарьларның эше канәгатьләнерлек дип табылды. 10 оешмада секретарь итеп яш коммунистлар сайланды.

(ТатТАСС).

☘

ЧЕПЬЯ. (**Телефон буенча**). Районнагы барлык башлангыч партоешмаларда отчет-сайлау җыелышлары тәмам булды. Отчет-сайлау җыелышлары большевистик тәнкыйть астында үттеләр. 9 оешманың эше канәгатьләнерлек дип, МТС һәм Райсоюз янындагы партоешмаларның эше канәгатьләнмәслек дип табылды.

Фәйзуллин.

Партиянең Ленин район конференциясе

25 нче февральдә кич 6 сәгатьтә Казан шәһәре Ленин районы большевикларының IV нче район конференциясе ачылды. Конференциягә тавыш бирү хокукы белән 137, киңәш бирү хокукы белән 27 делегат катнаша. Делегатлардан тыш конференциягә район партия активыннан 100 дән артык кеше катнаша. Шулай ук ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты секретаре Бычков, ВКП(б) Үзәк Комитеты янындагы Партия Контроле Комиссиясенең Татарстандагы уполномоченныйе Шмильков һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының Татарстан буенча парторгы Павлов иптәшләр катнашалар.

Озакка сузылган алкышлар астында почетлы президиумга башында иптәш Сталин торган Политбюро составы, Тельман, Димитров иптәшләр сайландылар.

Аннан соң конференция 15 кешедән президиум, 7 кешедән мандат комиссиясе һәм 5 кешедән секретариат сайлады.

Конференциянең көн тәртибендә торган беренче мәсьәлә буенча—отчет чорында райкомның эшләгән эшләре турында ВКП(б) райкомының беренче секретаре иптәш Ананьев доклад ясады.

Г. Миңнул.

КАДРЛАР ҺӘМ АЛАРНЫ ТӘРБИЯЛӘҮ

Яңа кадрларны тәрбияләп үстерү — партия оешмалары алдында торган төп бурычларның берсе. Партиябезнең XVIII нче съезды тарафыннан Сталинчыл өченче бишьеллыкта куелган политик һәм хуҗалык бурычларын үтәүдә кадрларны дөрес урнаштыру һәм тәрбияләп үстерү эше хәл иткеч урыннарның берсен тота.

ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң үткән чор эчендә, яңа, яш кадрларны дөрес сайлап алу, җитәкче постларга күтәрү һәм аларның теоретик белемнәрен арттыру өлкәсендә партия оешмалары зур эш башкардылар. Мисальгә ВКП(б) ның Шөгер район оешмасын алырга мөмкин. Партиянең тарихи XVIII нче съездыннан алып 1940 нчы елның 1 нче январена кадәр булган вакыт эчендә бу районда партияле һәм партиясез большевиклардан барлыгы 62 кеше партия, совет һәм хуҗалык оешмаларында җитәкче постларга күтәрелгән. Шулардан 34 кеше район күләмендәге һәм 28 кеше авыл күләмендәге җитәкче эшләргә күтәрелгән. Шунсы характерлы: җитәкче эшкә күтәрелгәннәр арасыннан 22 се ВКП(б) сафларына 1939 нчы елда кабул ителгән иптәшләр. Бу саннар безнең партиябезнең һәм дәүләтебезнең кадрлары соңгы ел эчендә тагын да ныграк үскәнлеген һәм бу үсеш чыннан да сыналган, тикшерелгән работниклар хисабына барганлыгын күрсәтә торган ачык мисальләр булып торалар.

Җитәкче эшкә күтәрелүчеләрнең тормыш һәм эш юлларын күрсәтү өчен кайбер иптәшләргә тукталып үтәргә кирәк. Менә, ВКП(б) райкомының оештыру - инструкторлык бүлегенә 1939 нчы елның июль аенда инструктор итеп күтәрелгән иптәш Николаев. Ул элек кулакларда батрак булып эшләгән, Иске Кувак авылы больницасында 3 ел буена дворник, Битум заводында 3 ел ат караучы, 1 ел кочегар булып эшләгән. Аннары, 3 ел буе шул ук заводта машинист булган. Башта ул укыйяза да белмәгән. Ул үзенең белемен күтәрү өстендә зур тырышлык күрсәтә: бик тиз арада үзлегеннән укып башлангыч мәктәпне тәмамлый. 1931 нче елны ул партиягә керә. Үзенең политик һәм гомуми белемен күтәрү өстендә тагын да ныграк шөгыльләнә башлый. 1935 нче елдан башлап 1939 нчы елның июленә кадәр иптәш Николаев Битум заводында башлангыч партоешманың секретаре булып эшли. Шушы чор эчендә партиянең бу оешмасы алдынгы кешеләр исәбенә көчле рәвештә үсә, коммунистларның производствода авангардлык рольләре күтәрелә, барлык коммунистлар да стахановчы булуга ирешәләр. Иптәш Николаев райком инструкторы буларак, үзенә йөкләтелгән эшләрне яхшы башкара, партиянең башлангыч оешмаларына практик эштә зур ярдәм күрсәтә. Коммунистлар арасында аның авторитеты зур.

Авыл күләмендәге җитәкче эшләргә дә шулай ук алдынгы кешеләр күтәреләләр. Менә иптәш Садыйков. Ул „Индустрия" колхозында 5 ел бригадир булып эшләгән. Аның бригадасы колхозда беренче урынны алып килгән. 1939 нчы елны аны шул колхозга председатель итеп күтәрәләр. Һәм иптәш Садыйковның дөрес җитәкчелеге аркасында бу колхоз политик-хуҗалык бурычларны үтәү өлкәсендә үзенең артталыгын бетерүгә һәм 1939 нчы елда районның алдынгы колхозлары сафына басуга ирешә.

Шөгер районында 1939 нчы елны җитәкче эшләргә күтәрелгәннәрнең гаят зур күпчелеге әнә шундый работниклар.

Райкомның һәм аның кадрлар бүлегенең эше кадрларны тегеяки бу постка күтәрү белән генә чикләнергә тиеш түгел. Җитәкче эшкә күтәрелгән работникларны һәр вакыт белергә, даими рәвештә өйрәнергә, партиянең һәм хөкүмәтнең директивалары алар эшли торган участкыда ничек үтәлүен тикшереп торырга, күтәрелгән работникларның эшне ничек оештырганлыкларын, эштәге кыенлыкларны ничек хәл кылганлыкларын белеп торырга, үзләренә йөкләтелгән бурычларны үтәүдә аларга ярдәм итәргә кирәк. ВКП(б) ның Шөгер райкомы бу өлкәдә кайбер эшләр үткәргән, ләкин алар әле һич тә җитәрлек түгел. Күтәрелгән кадрларга, аларның көндәлек эшләрендә булышлык күрсәтү, аларның гомуми, политик белем дәрәҗәләрен күтәрү өстендә эшләүләрен яхшырту мәсьәләләре белән райком җитәрлек шөгыльләнми.

Тагын да шуны әйтергә кирәк: 1939 нчы елда җитәкче эшкә күтәрелгән кадрлар арасында хатын-кызлар бик аз. Бу чор эчендә хатын-кызлардан бары 4 кенә кеше күтәрелгән. Бу—гомуми санга карата 6,6 процент кына дигән сүз. Бу факт Шөгер районында хатын-кыз кадрларны өйрәнү һәм аларны җитәкче постларга күтәрү эшенең канәгатьләнерлек куелмаганлыгын күрсәтә. Һәрбер райондагы кебек үк, бу районда да үзенең эшен үрнәк итеп куйган хатын-кыз бригадирлар, звеноводлар, уку өе мөдирләре, ферма работниклары, укытучылар һәм башкалар бик күп. Ләкин район оешмалары аларны тиешенчә өйрәнмиләр, кирәгенчә белмиләр, менә шуның аркасында бу эш канәгатьләнерлек хәлдә тормый. Бу зур җитешсезлек искә алынырга һәм киләчәктә кабатланмаска тиеш.

Иптәш Сталинның кадрларны сайлап алу ул: „... Үсеп килүче һәрбер работникка югары күтәрелүдә ярдәм итү, андый работниклар белән түземле рәвештә „мәшәкатьләнү" өчен һәм аларның үсүен тизләтү өчен вакытны кызганмау дигән сүз"ен төгәл үтәү өчен большевикларча көрәшергә кирәк.

И. Узбеков.

Казан Пехота училищесе курсантларыннан (сулдан уңга): Н. С. Чесняков, В. В. Шанцеев һәм И. А. Шичанин иптәшләр ВКП(б) тарихын өйрәнәләр.

М. Солтанов фотосы.

ТӨНГЕ СМЕНАЛАРДА АГИТАЦИЯ ЭШЛӘРЕН КӨЧӘЙТЕРГӘ

Советлар иленең тормышы гаять бай. Халкыбызның гүзәл эшләре һәм җиңүләре турында радио, матбугат яңадан-яңа хәбәрләр китереп тора.

Хезмәт ияләре боларның барсы турында да үз вактында белергә, тулы аңлату алырга телиләр. Ләкин безнең „Спартак" комбинатында бу эшкә—политик агитация эшенә җитәрлек игътибар бирелми әле. Бу эш төнге сменаларда аеруча начар куелган. Төнге сменаларда эшләүчеләр күбесенчә политик әһәмиятле вакыйгаларне вактында белми калалар. Мәсәлән, январь аенда Москва шәһәрендәге Инструменталь завод коллективының мөрәҗәгате иглан ителде. Бу мөрәҗәгаттә алар, илебезнең барлык эшчеләрен хезмәт җитештерүчәнлегенең бишьеллык планын дүрт елда үтәргә чакырдылар. Бу чакыру комбинатта беренче сменада эшләүчеләргә үз вактында җиткерелде. Ә төнге сменада эшләүчеләргә бу турыда бер нәрсә дә аңлатылмады.

Көндезге сменада, ял вакытларында партбюро членнары, профсоюз оешмалары җитәкчеләре, парторглар эшчеләр белән беседалар үткәрәләр. Ләкин төнге сменада масса - аңлату эшләре бөтенләй үткәрелми. Штамп цехында профсоюзның цех комитеты председателе иптәш Аюпова, парусин цехының парторгы төнге сменаларда агитация-масса эшләре алып баруны кирәксез саныйлар.

Ләкин бу дөрес түгел. Төнге сменаларда эшләүчеләр арасында агитация-масса эше алып бару өчен мөмкинлекләр бар. Бары тик эшләргә һәм оештыра белергә генә кирәк. Эшчеләр, бигрәк тә ерак торучылар эшкә күбесенчә берәр сәгать алдан киләләр. Эш башланганчы беседалар үткәрергә, газета-журналлар укырга, бик мөмкин. Ләкин бу нәрсә эшләнми.

Агитатор итеп билгеләнгән иптәшләр дә хәзер кирәгенчә эшләмиләр. Мәсәлән, Киус һәм Шаһвәлиева иптәшләрне алыйк. Җирле Советларга сайлаулар вактында алар сайлау участкыларында зур эш алып бардылар. Ләкин хәзер, цехта, бигрәк тә төнге сменаларда алар берниңди дә агитация-масса эшләре алып бармыйлар.

Комбинатның цехларында, төнге сменаларда йөзләрчә комсомолецлар һәм союздан тыш яшьләр эшлиләр. Эш башлангачы, ял сәгатьләрендә аларның тегеяки бу мәсьәлә буенча аңлатма аласылары, беседа тыңлыйсылары килә. Ләкин комсомол комитеты членнары цехларда булмыйлар.

Цехларда күргәзмә агитация материаллары да юк. Тегү цехында 1939 нчы елның 1 нче маена, октябрьнең XXII еллыгына карата язылган лозунглар эленеп тора. Стахановчылык хәрәкәтенең яңа формаларына, социалистик ярышның яңа бурычларына карата язылган бер генә лозунг та һәм витрина да куелмаган.

Политик агитация мәсьәләсе портбюро утырышына һәм гомуми җыелышка куеп тикшерелгәне юк.

„Спартак" комбинатында политик агитация һәм масса-аңлату эшләрен яхшыртуга игътибар көчәйтелергә тиеш.

Б. Корбанов, Д. Васин.

АВЫЛДА ПОЛИТИК-АГАРТУ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНЕҢ ЭШЛӘРЕН ЯХШЫРТЫРГА

Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды социализмнан теземле рәвештә коммунизмга күчү юлын билгеләп, хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләү мәсьәләсен өченче бишьеллыкта төп политик бурычларның берсе итеп куйды. Иптәш Сталин үзенең докладында болай диде: „Хәзер безнең дәүләтнең ил эчендә төп бурычы—хуҗалык - оештыру һәм культура - тәрбия буенча тыныч эштән гыйбарәт".

Партиябез алдында, дәүләт алдында торган барлык бурычларны хәл итү—ул, хезмәт ияләренең киң массасы арасында коммунистик тәрбия эшен киң оештыруга бәйләнгән.

Менә шуның өчен дә, партия, совет, комсомол һәм җәмәгать оешмалары хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләү, аларның политик аңлылыкларын һәм культура дәрәҗәләрен күтәрү, алардан коммунизмның актив һәм аңлы төзүчеләрен тәрбияләп үстерү мәсьәләләренә аеруча игътибар бирергә тиешләр.

Хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдә политик-агарту учреждениеләренең әһәмияте аеруча зур. Безнең Татарстан республикасында, аеруча соңгы елларда, политик-агарту учреждениеләренең киң челтәре үсте. Татарстанда хәзер 1.708 уку өе, 1.404 колхоз клубы, 2.029 көтепханә, 57 культура йорты һәм 960 кызыл почмак бар. Бу культура учреждениеләре һәм аларның эшенә тартылган актив хезмәт ияләрен тәрбияләү буенча һәм аларның политик аңлылыкларын күтәрү буенча зур эш үткәрделәр һәм үткәрәләр. Политик-агарту учреждениеләре Верховный Советларга һәм хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларга хәзерлек һәм аларны үткәрү вактында аеруча зур массовый тәрбия һәм культура-агарту эшләре алып бардылар. Хезмәт ияләренең җирле Советларына сайлаулар хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүнең һәм Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгән ун меңнәрчә яңа кешеләрне агитаторлар, пропагандистлар итеп актив эшкә тартуның гүзәл мәктәбе булды.

Шулай да, кайбер урыннарда, политик-агарту учреждениеләре үзләренең эшләрен соңгы көннәрдә йомшарта башладылар; агитация һәм масса эшендә ирешелгән гаять зур тәҗрибәне ныгыту урнына, аны йомшарту, яңа тартылган актив белән эшләүгә әһәмият бирмәү фактлары бар. Политик-агарту учреждениеләренең эшләрен идея-политик яктан тиешле югарылыкка күтәрү өчен безгә күп эшләргә кирәк әле. Көннең соравына җавап бирә алмый торган клублар һәм уку өйләре бездә бар әле. Мәсәлән, Минзәлә районының Тулбай, Усай, Ю. Тәкермән авылларында клублар ташландык хәлгә китерелгәннәр. Алар җиһазландырылмаган, ремонтланмаган.

Иске Мажын авылы уку өе турында Минзәлә РОНОсының инспекторы иптәш Викулов менә нәрсә яза: „Иске Мажын авыл советында культура-масса эшләре оештырылмаган. Уку өе өчен махсус бина булдырылмаган һәм ул клуб бинасына урнаштырылган. Клуб ремонтланылмаган, ягулык белән тәэмин ителмәгән, клубта салкын, стеналар һәм портретлар бозланган. Клуб янында бер төрле түгәрәк тә оештырылмаган". Мамадыш районының Түбән Ошма, Красная Горка авылларында, Чаллы, Аксубай, Кама Тамагы районнарында да мондый фактлар юк түгел.

Бу фактлар культура учреждениеләренә кайбер район оешмаларының игътибар бирмәүләре турында, аларга җитәкчелек итмәүләре турында сөйлиләр. Күп кенә РОНО һәм ВКП(б) райкомнарының кайбер работниклары клублар, уку өйләре эшләренең эчтәлеген, түгәрәкләрнең ничек эшләүләрен тикшерергә „вакыт таба" алмыйлар.

Политик-агарту учреждениеләренең кадрлары белән эш аеруча начар тора. Татарстандагы 1.676 клуб һәм уку өйләре мөдирләреннән бары тик 40 кеше урта белемле, 709 кеше түбән һәм башлангыч белемле. Барлык работникларның 57,3 проценты бу эштә бер елдан ким эшли. Клуб һәм уку өйләре мөдирләре арасында яш үсмер малайлар һәм кызлар да аз түгел. Чаллы һәм Минзәлә районнарның клуб һәм уку өйләре мөдирләре арасында урта белемле бер генә кеше дә юк. Шуңа карамастан, Минзәлә районында политик-агарту учреждениеләре работникларының читтән торып укулары оештырылмаган. Чаллы районында читтән торып укучылар булса да, алар арасында эш алып барылмый.

ВКП(б) ның район комитетлары клуб һәм уку өйләре мөдирләрен райком бюросында расларга тиешләр. ВКП(б) райкомнары бу эшне тормышка ашырганда политик-агарту учреждениеләре работникларының эшләрен яхшыртуга аеруча игътибар биреп, бу эшкә Ленин—Сталин партиясенә чын күңелдән бирелгән, политик белемле, оештыручанлык сәләте булган кешеләрне сайлап алырга тиешләр.

Партия оешмалары, коммунистик тәрбия эшенең хәзерге вакытта хәл иткеч әһәмиятле эш булуын истә тотарга тиешләр.

Без пропаганда органнарын һәр яклап ныгытырга һәм аларның эшләрен бүгенге көннең таләпләренә җавап бирерлек итеп оештырырга тиешбез. Политик - агарту учреждениеләре тирәсенә киң активны, колхозның атаклы кешеләрен—алдынгы комбайнчыларны, тракторчыларны, бригадирларны, сыер сауучыларны, агрономнарны, укытучыларны, врачларны һәм башкаларны тартырга кирәк.

Партия органнарына отчет-сайлаулар вактында партия оешмаларының җитәкчеләреннән без хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләү турында, кешеләрнең, коммунизм төзүчеләрнең аңында капитализм калдыкларын бетерү турында ВКП(б) ның XVIII нче съезды күрсәтмәләрен партоешманың ничек үтәвен сорарга тиешбез. Бу мәсьәләләр партоешмаларның отчет-сайлау җыелышларында тикшерелә торган үзәк мәсьәләләрнең берсе булырга тиеш һәм ул, хәзмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләү эшен тагын да яхшыртуга барлык коммунистларның һәм партиясез большевикларның игътибарын көчәйтер.

Х. Музагитов.

ВКП(б) Өлкә Комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге инструкторы.

ПАРТИЯ ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮДӘ ҖИТӘКЧЕ РАБОТНИКЛАР

Әлки районында 312 кеше ВКП(б) тарихын үзлекләреннән өйрәнәләр. Бу иптәшләрнең күбесе большевизмны үзләштерү өстендә тырышып эшлиләр һәм яхшы нәтиҗәләргә ирешәләр.

Мәсәлән, коммунист иптәш Гыйззәтуллин „Кыскача курс" ның 12 бүлеген дә өйрәнеп, һәрбер бүлек буенча конспект төзегән. Иптәш Гыйззәтуллин хезмәт ияләре депутатларының район советына депутат итеп сайланды. Колхозда агитколлективка җитәкчелек итә. Бу эштә дә ул зур инициатива күрсәтә һәм колхозчылар арасында политик-тәрбия эшләрен үрнәк булырлык итеп оештырды.

Партиянең совхоз янындагы башлангыч оешмасыннан менә иптәш Җәләлиев. Ул инде хәзер „Кыскача курс"ның 9 нчы бүлеген өйрәнгән һәм тулы конспект төзегән. Партия тарихын өйрәнгәндә марксизм - ленинизм классиклары әсәрләреннән һәм башка ярдәмче материаллардан да файдалана. Иптәш Җәләлиев партия тарихын урта буын буенча өйрәнүчеләр түгәрәгенә җитәкчелек итә. Аның дәресләре планлы рәвештә һәм яхшы хәзерлек белән үтәләр. Түгәрәкләрдәге эше турында иптәш Җәләлиев болай ди:

— Мин башта үзем занятиеләргә яхшылап хәзерләнәм. Барлык мәсьәләләр белән ныклап танышам. Шуннан соң инде түгәрәк членнарының занятиегә хәзерлекләрен тикшерәм. Алар белән индивидуаль беседалар, консультацияләр уздырам. Аңлашылмаган мәсьәләләрне бергәләп чишәбез. Шуның нәтиҗәсендә, занятиеләр җанлы үтәләр, һәрбер иптәш занятиедә актив катнаша.

ВКП(б) райкомының икенче секретаре Шәйхеттинев, район мәгариф бүлеге мөдире Медиков, райком пропагандистларыннан Шаранов һәм Яруллин, урта мәктәп директоры Лукоянов һәм башка күп кенә җитәкче работниклар партия тарихын өйрәнү өстендә, үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү өстендә тырышып эшлиләр һәм яхшы үрнәкләр күрсәтәләр.

Ләкин, райондагы җитәкче работниклар арасында үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү эшенә гамьсез караучылар да юк түгел. Мәсәлән, хезмәт ияләре депутатларының район советы башкарма комитеты председателенең урынбасары иптәш Яруллин башта партия тарихын түгәрәктә өйрәнергә булды. Ә соңыннан „Мин үзлегемнән өйрәнәм" дип, түгәрәк занятиеләренә йөрүне ташлады. Ләкин елдан артык вакыт үтүгә карамастан, иптәш Яруллин „Кыскача курс"ның беренче бүлегеннән уза алмаган. Райком инструкторы иптәш Веденеева исә, партия тарихын түгәрәккә йөреп өйрәнергә дә, үзлегеннән өйрәнергә дә „вакыт таба алмый". Район советы башкарма комитеты председателе Зәйнуллин, район җир бүлеге мөдире Гобәйдуллин, милициянең район бүлеге начальнигы Булатов, район колхоз мәктәбе директоры Веденеев һәм Әлки МТС ы директоры Бикулов иптәшләр дә үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү эшенә әһәмият биреп җиткермиләр. ВКП(б) ның Әлки район комитеты районда пропаганданың куелышын яхшырту буенча эшлекле чаралар күрергә тиеш.

Тамаков.

ФЕРГАНӘ ТӘҖРИБӘСЕН—ЮЛЛАР ТӨЗЕЛЕШЕНӘ!

ЮЛ ТӨЗЕЛЕШЕ СТАХАНОВЧЫЛАРЫ

Буденный районының „Радио", „Азат", „Земледелец" һәм „Ударник" колхозлары юл төзелеше планын Татарстанның XX еллык юбилей көненә 100 процент итеп үтәү йөкләмәсен алдылар.

Алар хәзер бу йөкләмәне үтәү өчен ныклы көрәш алып баралар. „Радио" колхозы таш чыгару һәм аны участкыларга ташу планын февральның беренче декадасында ук 125 процент үтәде. Колхозның юл төзелеше бригадасы членнары үзара ярышып эшлиләр. Район советы депутаты иптәш Ашимова бригаданың барлык членнарына үрнәк булырлык күрсәткечләр бирә һәм норманы 200 процент үти. Җамалеттинов, Наумитов, Баһаветтинова, Долгова һәм башка иптәшләр үз эшләрендә яхшы нәтиҗәләр бирәләр.

„Азат" колхозы членнарыннан Фәхреттинев, Рәхмитев, Садыйков һәм башка иптәшләр норманы 220—240 процент итеп үтиләр.

А. Яфизов.

Эшлексез комиссия һәм үтәлмәгән карарлар

Чистай районында авыл советлары, колхоз председательләренең һәм юл төзелеше алдынгыларының район киңәшмәсе булып үтте. Киңәшмәдә чыгып сөйләүче иптәшләр социалистик ярышны киң җәелдерергә сүз бирделәр һәм аларның күбесе киңәшмәдән кайту белән ныклы эшкә тотындылар. „Кызыл Сукачы", „Красный Октябрь" һәм Ленин исемендәге колхозлар юл төзелеше буенча махсус бригадалар оештырдылар, социалистик ярышны киң җәелдерделәр.

„Кызыл Сукачы" колхозы председателе Баһаветтинов, хисапчы Мифтахов иптәшләр бу эштә үзләре зур инициатива күрсәтәләр. Колхозчылардан Исмәгыйлев, Шәрәфеттинев, Зарипов иптәшләр норманы системалы рәвештә 200—220 процент итеп үтиләр. Алар социалистик ярыш договорларының үтәлешен әледән-әле тикшереп торалар. Моның нәтиҗәсе бик яхшы. Колхоз төзү материалларын ташуның еллык планын 110 процент итеп үтәде.

„Красный Октябрь" колхозы төзү материалларын эш объектларына ташуның еллык планын 73 процент, „Власть Советов" колхозы 60 процент һәм Ленин исемендәге колхоз 86 процент итеп үтәделәр.

Ләкин юл төзелеше планын начар үтәүче колхозлар да юк түгел. Бу эш буенча ВКП(б) райкомы янында төзелгән махсус комиссия үз бурычын үтәми, районда юл төзелешенә җитәкчелек итми. Комиссия председателе (райкомның икенче секретаре) Завьялов әлегә кадәр кыл да кыймылдатканы юк. Комиссия членнары колхозларда бөтенләй булмыйлар.

Райондагы 73 колхоздан 28 е юл төзү эшенә керешмәгәннәр дә әле. Мәсәлән, „Урожай" колхозы 450 кубометр төзү материаллары ташырга, моның өчен һәр көнне 17 ат, 13 кеше эшләргә тиеш. „Борьба за урожай" колхозы 418 кубометр, „Смена" колхозы 291 кубометр, Андреев исемендәге колхоз 418 кубометр төзү материаллары ташырга тиеш. Фактта исә алар бер генә кубометр да төзү материаллары ташыганнары юк әле.

Тулай районны алганда бу эш бөтенләй канәгатьләнерлек түгел. Районда юл төзелеше буенча һәр көнне 670 кеше урнына 156, 460 ат урнына 142 ат эшли. Бу өзеклек, ни өчендер, район җитәкчеләрен, аерым алганда юл төзелеше комиссиясе членнарын борчымый. ВКП(б) райкомы секретаре Аблялимов, райбашкарма комитеты председателе Жуков иптәшләр исә үзләре чыгарган карарларның үтәлешен тикшерү мәсьәләсе белән бөтенләй шөгыльләнмиләр.

К. Исламов.

АЛДЫНГЫЛЫКНЫ БИРМӘБЕЗ

Тымытык районы финанс планын үрнәк рәвештә үтәве өчен Татарстан Совнаркомының һәм Наркомфинның күчмә кызыл байрагын ике елдан бирле үз кулында саклый.

Районда уңышлар аз түгел. Моны саклык кассаларында вкладларның үсүе белән генә дә күрсәтеп була. Мәсәлән, 1937 нче елда вкладлар калдыгы 36 мең сум булса, 1940 нчы елның 1 нче январенә бу сан 181 мең сумга җитте. 1938 нче елда колхозчылар арасында 184 мең сумлык заем урнаштырылган иде. Ә узган ел өченче бишьеллык (икенче ел чыгарылыш) заемы 252 мең сумлык урнаштырылды һәм взнослар җыю эше уңышлы бара.

Тат. Шуган авыл советы заем взнослары җыю эшен районда беренче булып тәгәлләде. Авыл советы председателе, Хасан күле янындагы сугышларда катнашучы орденлы иптәш Абдуллин заем взнослары җыюда зур эшлелек күрсәтте. Монда барлыгы 15 мең 280 сумлык заем урнаштырылды. Сукаеш авылында да 28 мең 635 сумлык заем таратылып, взнослар срогыннан элек җыеп алынды.

Тымытык районы бу уңышларга бары тик масса арасында эшне яхшы оештыру һәм барлык чараларны финанс активистлары белән берлектә хәл итү нәтиҗәсендә иреште. Без финанс кадрларын дөрес урнаштыру, кемне, кайсы участкыга беркетү мәсьәләсе белән аеруча кызыксынабыз.

Безнең барлык финанс работникларыбыз һәм финанс активистлары үзара ярышып эшлиләр. Ярыш договорларының үтәлешен һәр ай саен тикшереп барабыз. Артта калучыларга социалистик ярдәм итү—ярыш договорларына төп пункт итеп кертелде.

Без Азнакай районы белән ярышып эшлибез. Алдынгылыкны 1940 нчы елда да бирмәбез.

Диаров.

Тымытык район саклык кассасы мөдире.

„Азат Хатын" артеле стахановчысы иптәш Х. Шаһиәхметова. Ул скорняк машинасында һәр ай саен эшләп чыгару нормасын уртача 250 процент үти һәм яхшы сыйфатлы продукция бирә.

И. Галиев фотосы.

ОТЛИЧНИК УКЫТУЧЫ МОХТАРОВА

Балаларны укыту һәм коммунистик тәрбияләү кебек почетлы һәм җаваплы эштә, иптәш Мохтарова 20 ел буена эшләп килә. Аның тәҗрибәсе гаять зур. Ул үзенең бөтен энергиясен, белемен, укучыларны тәрбияләүгә һәм аларны укытуга бирә. Укучыларда дуслык, иптәшлек һәм намуслылык тәрбияли.

Ул үзе укыта торган 3 нче класста (52 нче мәктәп) 3 елдан бирле 100 процент өлгереш биреп килә. Иптәш Мохтарова үзенең эше турында болай ди:

— Укытучы иң башлап балаларның дусты, өлкән иптәше һәм алар тарафыннан ихтирам ителә торган укытучы булырга тиеш. Укытучы балаларны яратсын һәм үзен дә алардан яраттыра белсен. Моның өчен балаларның характерын яхшы өйрәнергә, интереслары белән кызыксынырга һәм мәктәпнең көндәлек тормышында килеп чыккан аңлашылмаучылыкларны хәл иткәндә дөрес чишә белергә кирәк. Менә шулай эшләгәндә укытучының мәсьәләне дөрес хәл итүе турында укучыларда ышаныч туа. Бала үзенә карата сизгер булган укытучыны ихтирам итә. Балаларга шундый йогынты ясый алган укытучы аңлы дисциплинага ирешә һәм югары өлгереш бирә ала.

Ләкин һәрбер балага карата бер үк төрле методик алым кулланырга ярамый. 1937—38 нче уку елында минем класска ике бала алынды. Боларның берсе бик җыйнак, ләкин оялчан һәм куркак иде. Икенчесе бик җитез хәрәкәтле, ләкин шапшак йөри торган бала иде. Бу балаларны тәрбияләгәндә, мин аларның икесенә ике төрле методик алым кулландым һәм яхшы нәтиҗәләргә ирештем.

Иптәш Мохтарова үзенең 20 ел укыту дәверендә күп тапкырлар кабатланган темаларга да ныклап хәзерләнә һәм ул теманы бик күп төрле яңа материаллар белән баета. Дәресенә һәм ул дәреснең темасына карата күргәзмә материаллардан файдалана.

Иптәш Мохтарова өйгә эш бирүгә дә зур игтибар итә. Өйгә бирелгән эшнең үтәлешен системалы рәвештә тикшерә һәм ничек эшләү юлларын өйрәтә.

Иптәш Мохтарова отличник укытучы һәм актив җәмагать эшчесе. Ул, шәһәр күләмендә III нче класс укытучыларының секциясенә җитәкчелек итә. Методик докладлар ясый һәм күргәзмә материаллар хәзерли. Ачык дәресләр бирә. Аның ачык дәресләренә Сталин районындагы башлангыч мәктәпләрнең бик күп укытучылары йөриләр. Аның тарафыннан төзелгән тәрбия планы Казан шәһәрендәге башлангыч мәктәпләрнең 3 нче классында укытучылар өчен үрнәк булып тора.

М. Закирова.

Конкрет эшкә күчәргә вакыт

Ленин районындагы 68 нче мәктәп уку елының икенче чирегеn бары тик 65,1 процент өлгереш белән тәмам итте. 357 укучы укудан өлгермәде. Бу саннар мәктәптә отлично һәм яхшы уку өчен көрәшнең тиешле дәрәҗәдә оештырылмавын бик ачык күрсәтәләр.

Мәктәп директоры һәм комсомол оешмасы икенче чирекнең йомгакларына тулы анализ ясап, киләчәктә яхшы нәтиҗәләргә ирешү өчен конкрет чаралар күрергә тиешләр иде. Дөрес, мәктәптә бу турыда күп сөйлиләр, төрле киңәшмәләр, җыелышлар үткәреләләр. Ләкин хәл үзгәрми. Моны конкрет фактлар бик ачык раслыйлар. 2 нче сменада укучы 425 баладан 228 е укудан өлгерми. Ә аерым классларда, мәсәлән, иптәш Троицкая җитәкчелегендәге 7 нче „в" классындагы 40 укучыдан 37 укучы өлгерми.

Уку елын уңышлы тәмамлауда уку елының икенче яртысы хәл иткеч чор булып тора. Мәктәп янындагы партоешма һәм комсомол оешмасы моны аңларга һәм яхшы нәтиҗәгә ирешү өчен конкрет чаралар билгеләргә тиешләр.

А. Овчинников.

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ЛОНДОН, 22 февраль. Бүген көндез Англия истребительләре тарафыннан Англиянең төньяк-көнчыгыш яры якынында дошманның бер самолеты, Сейнт Абус Хед (Шотландия) янында икенче самолеты бәреп төшерелгәнлек турында рәсми рәвештә хәбәр ителә.

БЕРЛИН, 23 февраль. Германия армиясенең верховный командованиесе хәбәр итә: „Көнбатыш фронтта Мозель белән Пфальц урманы арасында оборонаның алгы өлешендә җанлы хәрәкәт. Апак районында Германиянең разведка частьләренең уңышлы хәрәкәтләре һәм Мерцигтан көнбатыштарак урманда урнашкан дошман отрядына уңышлы атака ясау нәтиҗәсендә берничә кеше пленгә алынды. Германия авиациясе Төньяк диңгез өстендә, Англия һәм Көнчыгыш Франция өстендә киң күләмдә разведка очышлары ясады. Германиянең 2 самолеты базага кайтмады. Англиянең Германия бухтасы өстендә очышлар ясаган „Виккерс Веллингтон" тибындагы 3 самолетының берсен Германиянең „Мессершмит" истребителе бәреп төшерде".

ПАРИЖ, 22 февраль. Гавас агентлыгы хәбәр итә: „Һава яхшыру аркасында көнбатыш фронтта җир өстендә һәм һавада операцияләр яңадан җанланып китте.

Саардан көнбатыштарак ике пунктта Германия патрульләре белән Франция патрульләре арасында бәрелешләр булды. Беренче бәрелеш нәтиҗәсендә немецләр таратылдылар һәм сугыш кырында күп санда коралларын һәм сугыш кирәк-яракларын калдырдылар. Француз солдатлары немецләрнең 2 унтер-офицерын пленгә алдылар.

Юлис елгасы секторында артиллериядән көчле атыш булды. Рейн фронтында елганың ике ягында урнашкан гаскәрләр арасында атышлар дәвам итә.

Берничә атна буена һава начарлыктан хәрәкәтсез яткан разведка авиациясенең дә эше яңарды. Һавада берничә бәрелеш булды, ләкин һичбер нәтиҗә булмады".

НЬЮ-ЙОРК, 22 февраль. „Нью-Йорк Таймс" газетасының хәбәренә караганда, 3 нче сентябрьдән 21 нче февральгә кадәр барлыгы 1.324.017 тонна авырлыктагы 380 сәүдә пароходы батырылган. Шулардан Англиянеке 169 пароход (648 мең тонна), Франциянеке 17 пароход (69 мең тонна), Германиянеке 29 пароход (151 мең тонна) һәм нейтраль илләрнеке 165 пароход (455 мең тонна).

ПАРИЖ, 22 февраль. Гавас агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Швециянең чит ил эшләре министре сугыш башланганнан бирле Швециянең 64 мең тонна авырлыгындагы 32 йөк пароходы батырылганлыгын белдергән. 228 моряк һәлак булган һәм 15 моряк хәбәрсез югалган. Аннары министр ачык диңгезләрдә нейтраль илләрнең үзләренең хокукларын бозуга каршы җавап хәрәкәтләре ясаулары мөмкин түгеллекне, чөнки бу хәлнең нейтраль илләрне сугышка тартачагын әйткән.

БЕРЛИН, 23 февраль. Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Германия самолетлары Англиянең „Тэртэн" һәм „Стэцнбэнк" исемле ике сакчылык карабын батырганнар.

Германия авиациясенең һөҗүме вактында Англиянең „Файфшир" траулеры батырылган. Команданың 2 офицеры һәм 19 кешесе һәлак булган.

ПАРИЖ, 23 февраль. Гавас агентлыгы Төньяк диңгездә диңгез көчләренең шактый активлашуын хәбәр итә. Монда Англия караблары Гельголанд атауларына һәм Боркум атавында Германиянең авиация базасына якын ук килгәннәр һәм немецләрнең миноносецларына атканнар. Немецләр дә Англиянең берничә сәүдә карабына һәм мина тральщикларына атака ясаганнар.

(ТАСС).

ДАНИЯ ЭШЧЕЛӘРЕ МАННЕРГЕЙМГА ЯРДӘМ ИТҮДӘН БАШ ТАРТАЛАР

КОПЕНҺАГИН, 23 февраль. (ТАСС). „Арбейдербладет"ның хәбәр итүенә караганда, порт эшчеләре профсоюзының Копенһаген оешмасы Маннергейм Финляндиясенә ярдәм итү турында профсоюзның реакцион җитәкчелеге такдимен үзенең җыелышында кире каккан. Җыелышта түбәндәге резолюция кабул ителгән: „Профсоюз Маннергеймга ярдәм итүдән баш тарта. Без Финляндия хезмәт ияләренең азатлык көрәшенә тирән симпатия белдерәбез һәм Англия — Франция империализмының агентлары булып Финляндияне сугышка һәм бәлаләргә китереп керткән маннергеймчыларның тиз җиңеләчәгенә ышанабыз. Шуның белән бергә без Советлар Союзына каршы кабахәт ялган һәм яла ягу кампаниясе алып баручы барлык газеталарга карата Дания хөкүмәтенең тиз арада чара күрүен таләп итәбез".

Газетаның хәбәр итүенә караганда, Копенһагинда Бур-Вайн фермасы эшчеләре һәм Эшбьерг шәһәре тимерчеләренең профсоюз оешмасы да ак финнәргә ярдәм итүдән баш тартканнар.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ УҢЫШЛАРЫ ТУРЫНДА ЭСТОНИЯ ГАЗЕТАСЫ

ТАЛЛИН, 23 февраль. (ТАСС). „Рахвалехт" газетасы Маннергейм линиясен Кызыл Армиянең өзүе турында хәбәр итеп болай дип яза: „Карелия бугазында Кызыл Армия хәзерге заманның ныкытмалары линиясенә атака ясап аны алды. Мажино һәм Зигфрид линияләре артында әле һаман да хәрәкәтсез торучы гаскәрләр өчен Финляндиядәге бу сугышлар бик гыйбрәтле. Маннергейм линиясендәге сугышлар Кызыл Армия сугышчыларының кыюлыгын һәм совет гаскәрләренең техника белән яхшы тәэмин ителгәнлеген күрсәттеләр".

Бөек һәм тарихи уңышлар планы

(ГОЭЛРО планының 20 еллыгына карата)

Советлар иленең халык хуҗалыгын яңа баштан коруда электрофикациянең гаять зур урын тотканлыгы партиябезнең IX нчы съезды карарларында бик ачык гәүдәләндерелде. „Съездда бердәм хуҗалык планы турындагы мәсьәләгә аеруча әһәмият бирелде, бу план, беренче чиратта, транспортны, ягулык эшен, металлургияне күтәрүне күздә тота иде. Бу планда төп урынны бөтен халык хуҗалыгын электрлаштыру турындагы мәсьәлә алган иде, электрофикацияне Ленин „10—20 ел өчен бөек программа" сыйфатында алга куйды. Соңыннан шушы нигездә атаклы ГОЭЛРО планы эшләнде, хәзер инде бу план бик күп арттырып үтәлде" (ВКП(б) тарихының кыскача курсы—272 нче бит).

Россияне электрлаштыру буенча 1920 нче елның февраль ае ахырларында оештырылган дәүләт комиссиясе (ГОЭЛРО), партиябез һәм хөкүмәтебез карарларын тормышка ашыру йөзеннән, Советлар республикасы халык хуҗалыгының беренче перспектив планын эшләде. 10—15 елга исәпләнгән ГОЭЛРО планы 1.500 мең киловатт көчлелегендә 30 электростанция төзүне, үзәкләштерелгән электроэнергия тәэминатын булдыруны күз алдында тотты. Шул ук вакытта авыл хуҗалыгы һәм җирле промышленность өлкәсендә зур булмаган электростанцияләре төзү мәсьәләсенә дә зур игтибар бирелде.

ГОЭЛРО ның Ленинчел-Сталинчыл планы алдынгы техника нигезендә, электрофикация нигезендә барлык халык хуҗалыгын үстерү буенча беренче генераль план булып хезмәт итте. Электрлаштыру программасы сугышка кадәр булган чорга караганда, промышленность товарлары эшләп чыгаруны ике тапкырга арттыруны, авыл хуҗалыгын техник яктан реконструкцияләүне билгеләде.

Советларның VIII нче съезды (1920 нче елның декабре) илебезне электрлаштыру буенча ГОЭЛРО планын яхшы дип тапты һәм бу бөек планны тормышка ашыру өчен үзенең конкрет күрсәтмәләрен бирде.

ГОЭЛРО планы бер илдә социализмның җиңүе турында Ленин һәм Сталин таглиматының конкрет чагылышы булды. Нак әнә шуның өчен аны төзгәндә һәм тикшергәндә халык дошманнары—капитализмның уң-троцкичы реставраторлары электрлаштыруга каршы ярсулы атака алып бардылар. Иуда-Троцкий электрлаштыру планына каршы, Ленинның кооператив планына каршы чыкты.

Ленин—Сталин партиясе бу көрәштә җиңеп чыкты, халык дошманнарын тар-мар итеп, ГОЭЛРО планын хуҗалык төзелешендә нигез итеп алды.

Электрлаштыруның бу бөек планы Ленин исән чагында ук тормышка ашырыла башлады. Юлда очраган авырлыкларны һәм шулай ук дошман каршылыкларын җимерә барган хәлдә, Советлар иле халык хуҗалыгын торгызуда бай тәҗрибә һәм зур көч туплады. Илебез электрлаштыру нигезендә халык хуҗалыгын индустрияләштерүгә юл тотты. Сөекле юлбашчыларыбыз Ленин һәм Сталин иптәшләр электростанция төзүчеләргә гаять зур ярдәм күрсәттеләр, төзелешләрне материаллар белән тәэмин итү мәсьәләсе белән турыдан-туры үзләре шөгыльләнделәр. Ленин сүзләре белән әйткәндә: „скромный башлангыч" 1920—21 нче елларда эшләнде. Бу чорда илебез электростанцияләрнең куәтен 12 мең киловаттка арттырды. 1922 нче елда Кашир станциясе ходка җибәрелде.

Даһи Ленин эшләрен дәвам иттерүче бөек Сталин җитәкчелегендә, СССР хезмәт ияләре илне электрлаштыру өлкәсендә гаять зур уңышларга ирештеләр. ГОЭЛРО планы кыска срокта—10 ел эчендә уңышлы рәвештә үтәлде. Электростанцияләребезнең куәте 1931 нче елда ук инде 3.972 мең киловаттка җитте. 1921 нче елны ул 1.228 мең киловатт иде. Бу чор эчендә электр-энергия эшләп чыгару 500 миллион киловатт сәгаттән, 10 миллиард 687 миллион киловатт сәгаткә җитте.

Сталинчыл бишьеллыклар чорында илебезнең электр промышленносте тагын да кызуырак үсте. Ватаныбызның төрле почмакларында гигант электростанцияләр төзелде. ГОЭЛРО планы кабул итү көненнән алып үткән 15 ел эчендә, 1936 нчы елда СССР дагы электростанцияләренең куәте 7.526 мең киловаттка, ә электр-энергия эшләп чыгару 32.827 миллион киловатт сәгаткә кадәр үсте.

Икенче бишьеллык ахрына электростанцияләребезнең куәте 8,2 миллион киловаттка җитте. ГОЭЛРО планында билгеләнгәнгә караганда 3 тапкыр артык дигән сүз. Электро-энергия эшләп чыгару икенче бишьеллыклар чорында 7,4 тапкырга үсте. Промышленность тарафыннан электроэнергия көченнән файдалану, 1913 нче ел белән чагыштырганда, 17 тапкырга артты.

Электро-энергиядән файдалану тимер юл транспортында аеруча үсте. Мәсәлән, электрлаштырылган тимер юллар озынлыгы 1932 нче елда 82 километр булса, 1937 нче елда ул 1.132 километрга җитте.

Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды тарафыннан расланган Сталинчыл өченче бишьеллыкта электрлаштыру эше тагын да киңрәк колач алды. Бу бөек эшләр планында 102 теплоэлектростанция төзү билгеләнде. Электростанцияләрнең гомуми куәте 17,1 миллион киловаттка, ә электроэнергия эшләп чыгару 75 миллиард киловатт сәгаткә җиткерелә. 1840 километр озынлыгындагы тимер юллар электрлаштырыла. Гигант Куйбышев гидростанцияләренең куәте 3,4 миллион киловатт күләмендә булачак.

ГОЭЛРО планы төзелә башлаганнан соң 20 ел үтте. Бу еллар халык хуҗалыгының барлык тармаклары буенча кызу рәвештә алга, коммунизмга бару юллары булды. Ильич лампалары, социализм утлары тагын да яктырак булып яна. Социализм—СССР хезмәт ияләренең тормышына керде, илебездә коммунизм җәмгыяте төзелә. Бу зур һәм тарихи уңышлар турыдан-туры бөек юлбашчыбыз, атабыз иптәш Сталин исме белән бәйләнгән.

Германия—Норвегия сәүдә килешүе төзелүгә карата

БЕРЛИН, 24 февраль. (ТАСС). „Дейче альгемейне цетунг" газетасы Германия белән Норвегия арасындагы экономик килешүгә багышлап махсус мәкалә басып чыгарды. Мәкаләдә бу килешүнең Германия белән Норвегия арасындагы товар әйләнешен тәртипкә салачагы күрсәтелә.

Германия белән Норвегия арасында экономик сөйләшүләрнең тиз һәм уңышлы тәмам булуы—сугыш булуга карамастан, ике илнең дә үзара сәүдә мөнәсәбәтләрен саклап калырга теләүләрен күрсәтә,—ди газета.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Япон гаскәрләренең февраль урталарында Цзяньтан елгасыннан көньяктарак башлаган һөҗүмнәре кире кагылган. Япон частьләре башта бераз алга киткәннәр иде, ләкин соңыннан кытайлар аларны кысрыклап кире чигендергәннәр. Кытай гаскәрләре бу районда Сяошаньнан башка барлык пунктларны кире алганнар. Сугышлар дәвам итә. Каншань якынында япон гаскәрләренең 2.500 дән артык кешесе үтерелгән һәм яраланган. Кытайлар 4 кыр орудиесе, 12 пулемет һәм берничә йөз винтовка кулга төшергәннәр.

21 нче февральдә Аньхуэй провинциясендә, Дунлю районында Янцзи елгасында кытайлар артиллериясе японнарның сугыш транспортына атып җидди зарарлар китергән.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Суйюань провинциясенең көнбатыш өлешендә кытай гаскәрләре Сыляны һәм күп кенә башка пунктларны алып, Уюань шәһәренә якынайганнар. Японнар тылында хәрәкәт итүче кытай частьләре Уюань белән Баотоу арасында хәбәрләшүне өзгәннәр.

Көньяк Кытай фронтындагы хәл турында хәбәрләр юк.

КЫТАЙДАГЫ СУГЫШНЫҢ ПЕРСПЕКТИВАЛАРЫ ТУРЫНДА ГЕНЕРАЛ БАЙ ЦЗУН-СИ

ЧУНЦИН, 23 февраль. (ТАСС). Сентрал Ньюс агентлыгы генерал Бай Цзун-синың белдерүен иглан итә. Бу белдерүдә ул Кытайның тәмам җиңәчәгенә ышаныч белдерә. Бай Цзун-си болай ди: Япония мөмкин булган 80 дивизиясеннән 50 сен туплады. Японнарның 46 лап дивизиясе Кытайда һәм аларның барсына да диярлек 30 тапкырдан артык өстәмә көчләр китерелде. Япония Кытай белән сугышуга 20 миллиард иенадан артык акча тотты инде. Японияның эчке бурычы көннән-көн арта. Японияның экономик мөмкинлекләре аңа озак сугыш алып барырга мөмкинлек бирмиләр. Кытайның исә коралы каршылык күрсәтү телэге үсә бара.

Чит илләрдә

ЭШЧЕ-КРЕСТЬЯН КЫЗЫЛ АРМИЯСЕНЕҢ XXII ЕЛЛЫГЫ УҢАЕ БЕЛӘН СССР НЫҢ БЕРЛИНДӘГЕ ИЛЧЕЛЕГЕНДӘ КИЧӘ

БЕРЛИН, 24 февраль. (ТАСС). 23 нче февральдә Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгын бәйрәм итү уңае белән СССР ның Берлиндәге илчелегендә кичә үткәрелде.

Кичәдә Германия армиясенең баш командующие генерал Браухич, Германиянең кораллы көчләренең югары командованиесе җитәкчесе генерал Кейтель, адмирал Ветцель, генерал Удет һәм Германиянең күп кенә башка күренекле хәрби чиннары булдылар. Кичәдә Германиядәге барлык чит ил илчелекләренең хәрби атташеләре катнаштылар.

СССР ның Германиядәге тулы хокуклы вәкиле иптәш Шкварцов җыелган кунакларны кыскача речь сөйләп котлады һәм СССР халыклары өчен Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгының әһәмиятен күрсәтеп үтте. Германиянең баш командующие генерал Браухич җавап рече сөйләде. Ул Советлар Союзының тыныч тәзелешендә Совет армиясенең гаять зур әһәмиятен күрсәтеп үтте. Генерал Браухич, Совет армиясе һәм флоты гаять зур культура бурычларын хәл иттеләр, дип күрсәтте. Ул болай диде: „Советлар Союзының коралды көчләре үсешен бөтен дөнья һәм бигрәк тә Германия зур игтибар белән күзәтеп бара".

Кичә дуслык шартларында үтте.

ЧУНЦИНДА СССР ИЛЧЕЛЕГЕНДӘ КАБУЛ ИТҮ

ЧУНЦИН, 24 февраль. (ТАСС). Кичә Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы уңае белән СССР ның Чунциндагы илчелегендә кабул итү булды. 200 кунак арасында Кун Сян-си, Сунь-Фо, Фын Юй-сян, чит ил эшләре министре Ван Жун-гуй, сугыш министре Хо Ин-цин, элемтә һәм тимер юллар министре Чан Цзяао, Чунцин шәһәр башлыгы У Го-чэн, оборона верховный советының генеральный секретаре Чжан Цюнь, 8 нче армия штабы вәкиле генерал Е Цзе-ин һәм башкалар бар иде.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ XXII ЕЛЛЫГЫ ТУРЫНДА ЧИТ ИЛ МАТБУГАТЫ

ЛИТВА

КАУНАС, 23 февраль. (ТАСС). Бүген Литваның бөтен матбугаты Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына багышланган мәкаләләр басып чыгарды. Газеталар күренерлек урыннарда иптәш Ворошилов портретын урнаштыралар.

„ХХ амжиус" иптәш Ворошиловның биографиясен һәм аның ВКП(б) ның XVIII нче съездында сөйләгән реченнән өземтәләр басып чыгарды. Бу речьтән өземтәләрне Литваның башка газеталары да урнаштырдылар.

ЛАТВИЯ

РИГА, 23 февраль. (ТАСС). Бүген Латвиянең бөтен матбугаты Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгын киң күләмдә билгеләп үтә. Газеталар Сталин һәм Ворошилов иптәшләрнең портретларын урнаштырдылар һәм Кызыл Армиянең тормышын күрсәтә торган фотографияләр бирделәр.

„Латвияс карейвис" газетасы болай дип яза: „Латвия белән Советлар Союзы арасында үзара ярдәмләшү турында төзелгән пактның ике дәүләт арасында киләчәктә дә бергәләп эш итүнең һәм үзара ышанычның нигезе булачагына без нык ышанабыз. Бөек күршебезгә һәм аның армиясенә иң яхшы уңышлар телибез".

ГЫЙРАКТА ЯҢА ХӨКҮМӘТ

ЛОНДОН, 23 февраль. (ТАСС). „Таймс" Гыйракта элекке баш министр Нури Сәет җитәкчелегендә яңа хөкүмәт төзелү турында хәбәр итә. Яңа кабинетның составы үткән составтан бөтенләй диярлек аерылмый. Анда бары тик министрлек портфельләре генә бераз башкача бүленгән. Армиянең югары командованиесенең күп кенә чиннары, шул исәптән генеральный штаб начальнигы һәм беренче дивизия командиры отставкага чыгарылганнар. Газетаның хәбәр итүенә караганда, алар хөкүмәтнең составын үзгәртүне, аерым алганда аның составыннан Нури Сәетне һәм шулай ук сугыш министре Таха Һашимины чыгаруны яклаганнар.

БЕРЛИН, 23 февраль. (ТАСС). Германиянең Трансоцеан агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Гыйракның элекке баш министре, Англия яклы Нури Сәетнең властька кире кайтуы Англиянең хәрби властьлары басымы астында килеп чыккан.

Югары командование кешеләрен Гыйрак армиясеннән отставкага чыгаруга карамастан, армиядә чуалышлар дәвам итә.

Балтач урта мәктәбенең допризывниклары Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы хөрмәтенә Балтач—Казан арасында чаңгыда чабыш оештырдылар. РӘСЕМДӘ: сулдан уңга—утырганнар: А. Гыйльмуллин, Г. Хаҗиәхметов, А. Хөснеттинов, басканнар: А. Гыйльметтинов һәм Н. Һадиев иптәшләр. И. Галиев фотосы.

Осоавиахимның 14 нче лотереясе

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Осоавиахимның 14 нче Бөтенсоюз лотереясен чыгарырга рөхсәт итте.

СССР Осоавиахимы Үзәк Советының карары буенча лотерея билетларын урнаштыру 15 нче апрельдә башлана. Лотерея билетлары буенча тираж шушы елның ноябрендә үткәреләчәк.

Орденлы Татарстан республикасының хезмәт ияләре, барлык совет халкы кебек үк, хөкүмәтнең бу карарын зур шатлык белән каршылар.

Осоавиахимга яңа лотерея чыгарырга рөхсәт итүе белән, Совет хөкүмәте Осоавиахим оешмаларына хезмәт ияләре арасында масса-оборона эшен тагын да киңрәк җәелдерергә, яңа аэроклублар, кавалерия мәктәпләре, тирлар һәм өйрәтү пунктлары ачарга мөмкинлек бирә. Болар барсы да социалистик Ватаныбызның оборона сәләтен тагын да күтәрүгә ярдәм итәчәкләр.

Осоавиахимның 14 нче лотереясе 200 миллион сумлык итеп чыгарыла. Шулардан 100 миллион сумы бишәр сумлык, 75 миллион сумы өчәр сумлык, 25 миллион сумы берәр сумлык билетлар булачак. Яңа лотерея буенча 25 миллион сумлык 410.000 отыш уйнала. Бишәр сумлык билетлар буенча 100 сумлыктан алып 27.000 сумлыкка кадәр отышлар уйналачак. Өчәр сумлык билетларга 60 сумлыктан алып 10.000 сумлыкка кадәр, берәр сумлык билетларга 20 сумлыктан алып 3.500 сумлыкка кадәр отышлар чыгарга мөмкин.

Осоавиахимның барлык работниклары, Осоавиахимның шәһәр, район советларының һәм башлангыч оешмаларының председательләре 14 нче лотерея билетларын урнаштыру өчен хәзерлек эшләренә керешергә тиешләр.

Лотерея кампаниясен уңышлы рәвештә тәмам итүчеләр бүләкләнәчәкләр. Осоавиахимның шәһәр һәм район советларын бүләкләү өчен 3.000 сумнан алып 15.000 сумга кадәр 25 премия, Осоавиахимның башлангыч оешмаларын бүләкләү өчен 500 сумнан алып 5.000 сумга кадәр 80 премия билгеләнде. *А. Сәлахеттинов.*

ТАННЕР ТАЯ

Казынды финнәр ягында
Дөньяның банкирлары:
Янәсе, борын тыгарга
Җайлы як Балтыйк ягы.

Биш-алты еллап мәтәште
Бетоннар коя-коя:
Алынмый торган, янәсе
Ныгытма кора була.

Ноталар язылды аңа:
Маташма, күрше,—диеп,
Төзәтик ике араны,
Аңла син сүзне,—диеп.

Ә Таннер тубын төбәде
Советлар Ватанына:
Аласы килгән, күрәсең,
Танавы тарафына!

Кем уйный безнең татулык
Телеграммасы белән,
Сал аңа Ворошиловны
Килограммасы белән!

Ямыйлар безнең ударлар
Ак финнең яңагына,
Һәм Лондон банкирларының
„Хөрмәтле" танавына.

Бетонлы ныгытмалардан
Таннерың тылга тая.
Большевик алалмый торган
Крепосте аның кая!?

Кем уйный безнең татулык
Телеграммасы белән,
Сал аңа Ворошиловның
Килограммасы белән!

Хәсән Туфан.

Фәнни работникларның яңа хезмәтләре

Казан Авыл Хуҗалыгы институтының фәнни работниклары колхозчыларга, совхоз һәм МТС эшчеләренә күп кенә яңа әсәрләр бирәләр. Академик В. П. Мосолов „Дөрес чәчү әйләнеше нигезендә агротехника" дигән китап язу өстендә эшли. Доцент Р. Р. Хөсәеневнең „Татарстанда бөртекле-кузаклы ашлыклар", доцент А. Ф. Демидовичның „Корылык шартларында бәрәнге үстерү", академик В. П. Мосолов һәм агроном А. Ф. Таранухинның „Люцерна агротехникасы" дигән китаплары рус һәм татар телләрендә басылып чыгачаклар. Академик Мосоловның „Уҗым культураларының һәлак булуына каршы көрәштә агротехника" дигән китабы татар теленә тәрҗемә ителә. Доцент Ибраһим Үтә көлсу туфракларда тирән сөрү методлары турындагы китабын рус һәм татар телендә чыгару өчен хәзерли. Шулай ук, доцент С. А. Ильин „Советлар Союзындагы алдынгы МТС ларның эш тәҗрибәләре" һәм ассистент Ш. В. Галиев „Татарстан колхозларында һәм МТС ларында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү" дигән китапларны язу эшен тәмамлап киләләр.

Авыл хуҗалыгын оештыру кафедрасы колхозларның кырчылык бригадаларында даими звенолар, колхозларны идарә итү эшләрен оештыру, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү һәм Татарстанда колхоз төзелеше экономикасы мәсьәләләре буенча 1939 нчы елдан бирле зур эш алып бара.

Ильин һәм Галиев иптәшләрнең „Колхозларның кырчылык бригадаларында даими звенолар" һәм доцент Ж. Х. Хәйруллинның „Чүп үләннәргә каршы көрәштә агротехник чаралар" исемле китаплары шушы көннәрдә генә басылып чыктылар. Иптәш Хәйруллин хәзер күп еллык үләннәрне өйрәнү белән шөгыльләнә. Ул клевер, люцерна, эспарцет, житняк һәм Америка сарутын нинди культуралар астына чәчәргә икәнлекне, аларга төрле ашламаларның тәэсирен, люцерна һәм эспарцетның корылыкка чыдамлыкларын, гомумән бу үләннәрнең үзенчәлекләрен өйрәнү буенча тикшеренүләр алып бара һәм шул темага китап язарга хәзерләнә.

Я. Б

ДРАМТҮГӘРӘК

Апас районы, Зур Күк-күз авылында, колхоз клубы янында төзелгән драмтүгәрәк күңелле генә эшләп килә. Түгәрәктә катнашучы яшьләр тарафыннан күп кенә постановкалар куелды. Болар арасыннан: „Галия Бану", „Чаткылар", „Уйнаш", „Беренче Театр", „Гаепсездән гаеплеләр" һәм „Бүләк өчен" постановкалары колхозчы масса тарафыннан аеруча җылы каршыландылар. Түгәрәк членнарыннан Мифтахов, Галиева, Камалов, Сәмитова, Кәлимуллин иптәшләр үзләрен яхшы гына таныттылар.

Ләкин, авылда яшьләр күп булуга да карамастан, комсомол оешмасы алар арасында җитәрлек эш алып бармый. Драмтүгәрәктән башка түгәрәкләр оештырылмаган. Клуб мөдире Гариф иптәш Кәлимуллин бары тик драмтүгәрәк белән генә мавыгып, башка эшләрне оештыруны онытып җибәрә.

Клубка радиоалгыч куйдыру, уку өсен әдәби китаплар һәм газета-журналлар белән баету турында да кайгыртырга кирәк.

С. Камал.

ТЕРЛЕКЧЕЛЕК ФЕРМАСЫНДА

Ленин исемендәге колхозның (Норлат районы) сыер асраучылык фермасында 177 баш сыер, 4 баш нәсел үгезе бар.

1939 нчы елда һәр сыердан уртача 1.700 литр сөт савып алынды. Колхоз үткән ел фермадан 34.000 сум доход алды.

Бу ферма 1939 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашты.

ОБОРОНА БӘЙРӘМЕ

Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына багышлап 24 нче февральдә Казанда зур күләмдә оборона бәйрәме үткәрелде.

Стадионнарда спорт җәмгыятьләренең хоккей командалары физкультура-спорт Комитетының призы өчен ярыштылар, „Динамо" җәмгыятенең чаңгы станциясендә „Динамо" һәм „Наука" спорт җәмгыятьләренең чаңгычылары кросс үткәрделәр. Бу кросста бер үк вакытта чаңгы буенча ГТО комплексы нормалары тапшырылды. Кроссларны шулай ук үз станцияләрендә башка җәмгыятьләр дә үткәрделәр.

Бәйрәм программасының иң зур һәм иң кызыклы өлеше Ирек мәйданында һәм Черекkүл бакчасында үткәрелде. Спортчыларның һәм осоавиахимчыларның граната ыргыту, мотоциклга тагылган хәлдә чаңгыда йөрү һәм противогазлар кигән хәлдә чаңгыда йөрү осталыкларын 3.000 нән артык кеше күзәтеп торды.

Ирек мәйданы уртасында кечкенә флаглар белән билгеләп, киңлеге 80 сантиметр, буе 10 метр зурлыкта „окоплар" ясалган. Граната ыргытучылар мәгълүм дистанциядән торып гранатаны шул „окопка" төшерергә тиешләр. „Окопка" туры килгән һәр ыргыту 100 очко бирә. Аннары, мәйданның урта бер җирендә 4 метр ара калдырып ике яклап баулар сузылган. Бу бауларга нәни кызыл флаглар эленгән. Биш гранатадан торган бәйләмне әнә шул ике бау арасындагы „коридордан" читкә чыкмаслык итеп мөмкин кадәр еракка ыргытырга кирәк. 10 метрдан арткан һәрбер метр 100 очко бирә. Аннан соң, Черекkүл бакчасының югары ягында махсус стойкаларга биеклеге 3 метр, киңлеге 70 сантиметр күләмендә „тәрәзәләр" ясалып куелган. Гранатаны мәгълүм дистанциядән әнә шул „тәрәзәгә" кертерлек итеп ыргытырга кирәк. „Тәрәзәгә" туры китерелгән һәр ыргыту 100 очко бирә.

Граната ыргыту ярышларында Казан Химия-Технология институты студентлары—Кисенко (1.400 очко) һәм Лачугина (1.700 очко) иптәшләр һәм Казан Дәүләт университетының физкультура укытучысы иптәш Панкова (1.700 очко) беренче урыннарны алдылар.

Мотоцикл-чаңгы ярышларында „Учитель" спорт җәмгыятеннән мотоциклист иптәш Благодаров һәм чаңгычы иптәш Благовидов 18 километр дистанцияне 45 минут 15 секунд эчендә үтеп, финишка беренче булып килеп керделәр.

Осоавиахимның Ворошиловчы кавалеристларының ат өстендә йөрү осталыкларын да халык бик кызыксынып карады.

Редакциягә хат

Татарстан АССР ның В. И. Ленин исемендәге Үзәк китапханәсе работниклары коллективы, китапханәнең 75 еллыгы бәйрәмендә катнашкан һәм китапханә коллективын котлаган барлык оешмаларга һәм аерым кешеләргә газета аркылы чын күңелдән рәхмәт белдерә.

Китапханә работниклары коллективының тапшыруы буенча, директор *Мөхеттинова.*

БЕЛДЕРҮ

Бүген кич 6 сәгатьтә язучыларның Г. Тукай исемендәге кабинетында балалар әдәбияты секциясенең чираттагы җыелышы була.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

ТАТНАРКОМПРОС

Районнардагы тулы булмаган урта мәктәпләрдә эшләү өчен, тарихтан, рус теле һәм әдәбиятыннан, татар теле һәм әдәбиятыннан, немец теленнән, физикадан һәм математикадан — укытучылар хәзерләү буенча 6 айлык курслар ача

Курсларга 18 яштән түбән булмаган һәм тәгәлләнгән урта белемле кешеләр алыналар.
Урта мәктәпнең 8 классын тәгәлләгән кешеләр сынау үтү белән алыналар.
Курсларга алынганнарга стипендия һәм квартира акчасы бирелә.
Укулар 10 нчы марттан башлана.
Гариза белән бергә, керүченең автобиографиясе, белеме турында документ, яше турында һәм хезмәте урыныннан белешмәләр бирелергә тиеш.
Гариза җибәрү өчен адрес: Казан, Комсомол урамы, 38 (12 нче мәктәп), курслар дирекциясе. 363—1

„ГЛАВКИНОПРОКАТ" НЫҢ ТАТАРСТАН БҮЛЕГЕ
якын көннәрдә Татарстан АССР кино-экраннарына, Киев киностудиясендә эшләнгән

исемле тавышлы, художестволы яңа фильм бирә.
П. Нилин сценарийсы. Режиссер Л. Луков.
Баш рольләрдә: артистлардан—Б. Андреев, П. Алейников, И. Пельтцер, И. Новосельцев, Л. Масоха.
Фильм бүгенге Донбасс турында, мактаулы Донбасс шахтерлары арасыннан чыккан гүзәл кешеләр турында сөйли.

СССР СОВНАРКОМЫ ЯНЫНДАГЫ Совет Контроле Комиссиясенең Татарстандагы уполномоченные

Кремльдә, Совконтрольнең элекке бинасында урнашты. Вакытлыча телефон УКСК — 20 — 97. Секретариат мөдире 12—53, контролерлар: 4—72, 5—24 һәм 4—55; җалобалар контролеры 9—24. 362—1

МОСТАРА ТРЕСТЫНЫҢ КАЗАН КОНТОРАСЫ
Чернышевский урамындагы 2 нче йорттан Париж Коммунасы урамындагы 21 нче йортка
КҮЧТЕ 276—1

Хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитетының карары нигезендә, шушы ел 24 нче февральдән,
9 һәм 10 нчы маршрут трамвайларында йөрү өчен
түләү бәяләре буенча
БЕРДӘМ ТАРИФ КЕРТЕЛДЕ:
1. Шәһәрдән Серго Орджоникидзе исемендәге заводның иске управлениесенә кадәр (диспетчер пункты) 15 тиен.
2. Иске управлениедән Серго Орджоникидзе исемендәге заводка кадәр (9 нчы маршрутның ахыры) 15 тиен.
3. Серго Орджоникидзе исемендәге заводның иске управлениесеннән (диспетчер пунктыннан) шул ук заводның ИТР лар поселкасына кадәр (10 нчы маршрутта) 15 тиен.
4. Шәһәрдән Серго Орджоникидзе исемендәге заводка кадәр 30 тиен. 353—2—1

КИРӘК:

„Авиапромснаб" Казан конторасының транспорт бүлегенә даими эшкә ШОФЕРЛАР һәм СЛЕСАРЬЛАР. Федосеевский урам, 9. 229—2—1

Татарстан АССР НКВД ның хезмәт колонияләре бүлегенә ПРОИЗВОДСТВОЧЫ ИНЖЕНЕР, БАШ БУХГАЛТЕРЛАР, ТОВАР ҖИТЕШТЕРҮ БУЕНЧА ЭШЛӘҮЧЕЛӘР һәм ХӘРБИЛӘШТЕРЕЛГӘН ОХРАННИКЛАР. Казан, Чернышевский урамы, 12/20, кадрлар бүлеге. 215—3—3

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Автомобиль Транспорты идарәсенә, баш инженер хезмәтләрен үтәү өчен, АВТО ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ИНЖЕНЕР. Казан, Островский урамы, 20. 253—2—2

Татпромпроектка, эш башыннан эшләү өчен, проектлаштыру эше буенча кимендә 3 еллык стажлы ПРОЕКТЛАШТЫРУЧЫ-ТӨЗҮЧЕ - РАСЧЕТЧЫ ИНЖЕНЕРЛАР. Татпромпроектка килергә. Казан, Татарстан һәм Комсомол урамнары чаты, 17/2. 269—2—2

Хезмәт Саклау институтына ИНЖЕНЕР-КОНСТРУКТОРЛАР, ИНЖЕНЕР - МЕХАНИК һәм ЛАБОРАНТ. Комлев урамы, Хезмәт сарае, 29 нчы бүлмә. 357—1

Индивидуаль заказлар буенча аяк киемнәре тегү мастерскоена даими эшкә КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ ИТЕКЧЕЛӘР һәм БАШМАКЧЫЛАР. Университет урамы, 2/51. Телефон 11—48. 359—5—1

Васильево Урман комбинатына даими эшкә, КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК ТЕХНИКАСЫ һәм ХЕЗМӘТ САКЛАУ ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ИНЖЕНЕР. Хезмәт хакы килешү буенча. Квартира бирелә. Казан тимер юлының Васильево станциясе, Лесокомбинат конторасы. 361—2—1

Казан Психатрия больницасына даими эшкә ХИСАПЧЫЛАР, МАШИНИСТКАЛАР, ОХРАННИКЛАР, ДИПЛОМЛЫ КОЧЕГАРЛАР, СЛЕСАРЬ-МЕХАНИКА ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА НОРМАЛАУЧЫЛАР һәм ТӨЗЕЛЕШ ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР. Казан, Ершов кыры, 5 (3, 6 һәм 8 нче маршрут трамвайлары). Телефоннар: 4—27 һәм 32. 337—3—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 26 нчы февральдә
БУЛАК АРТЫ „РЕСПУБЛИКАСЫ"
Талон 124.
Спектакль кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык.
ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн
РСФСР ның атказанган артисты орденлы
М. ЗОЛЛО
гастрольләре
Яңартылган репертуарда көлке номер:
„МӘЕТ КҮМҮ"
Хайваннар башкаруында һәм башка номерлар.
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

КАЗМЕХКОМБИНАТНЫҢ
Н. К. Крупская исемендәге
ФЗУ МӘКТӘБЕ
мех әйберләре тегү буенча югары квалификацияле тегүчеләр хәзерләү өчен
УКУЧЫЛАР АЛА
УКУ СРОГЫ 1 ЕЛ.
Мәктәпкә 17—18 яштәге һәм 6—7 класс күләмендә белемле хатын-кызлар алыналар.
Гариза белән бергә, керүченең белеме һәм яше турында белешмәләр бирелергә тиеш.
Мәктәпкә алынганнарга, аларның академик һәм практик өлгерешләренә карап, айга 70 сумнан 130 сумга кадәр стипендия бирелә.
Күрсәтелгән документлар белән гариза җибәрү өчен адрес: Казан, Яңа бистә, Кече Ямашев урамы, 71. Телефон 44—14. 182—4—1

ГОРЖИЛСНАБ
Чернышевский урамындагы 2 нче йорттан Астрономия урамындагы 8 нче йортка
КҮЧТЕ. 268—2—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
26 һәм 27 нче февральдә премьера
ЛЕНИН
Талоннар: бүген 109, иртәгә 110.
Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ХЕЗМӘТ ХАЛКЫ УЛЛАРЫ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8 һәм 10 да	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„Колхозник" 4, 6, 8 һәм 10 да.	КЫЗЫЛ АРМИЯ
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9 - 30 да.	ЗЕЛИМХАН
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6, 8, 10 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ. Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яшьтәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ" 4, 6, 8, 10 да.	БАЛТЫЙКЧЫЛАР
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	БЕЗ КРОНШТАДТТАН

Су станциясе территориясендә „ДИНАМО" ның
ЧАҢГЫ СТАНЦИЯСЕ
БГТО һәм ГТО буенча I һәм II нче баскыч нормалар тапшыру өчен, шулай ук коллектив һәм индивидуаль рәвештә чаңгыда йөрергә чыгу өчен файдаланырга, махсус ботинкалары белән, чикләнмәгән күләмдә
чаңгылар бирә
Ботинкалары белән чаңгылардан файдалану өчен бер сәгатькә түләү бәясе: индивидуаль алучылар өчен 1 сум, коллектив рәвештә алу өчен—75 тиен. 322—3—3

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 730 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА. ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 770.